ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20 июль 2023 ел № 6461

Акцияләренең (өлешләренең) йөз проценты Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенә караган муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренә һәм хезмәткәрләренә, муниципаль унитар предприятиеләр җитәкчеләренә, аларның урынбасарларына һәм баш бухгалтерларына һәм хуҗалык җәмгыятьләре җитәкчеләренә хезмәт командировкасына бәйле чыгымнарны кайтару турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 168 статьясының 3 өлеше, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хезмәткәрләрне хезмәт командировкаларына җибәрү үзенчәлекләре турында» 2008 елның 13 октябрендәге 749 номерлы карары, шәһәр Уставының 41 статьясы, шәһәр Советының 2022 елның 26 декабрендәге 19/4 номерлы карары белән расланган акцияләренең (өлешләренең) йөз проценты Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенә караган муниципаль унитар предприятиеләр һәм хуҗалык җәмгыятьләре җитәкчеләрнең, аларның урынбасарларының, баш бухгалтерларының хезмәт өчен түләү шартлары һәм тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Акцияләренең (өлешләренең) йөз проценты Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенә караган муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренә һәм хезмәткәрләренә, муниципаль унитар предприятиеләр җитәкчеләренә, аларның урынбасарларына һәм баш бухгалтерларына һәм хуҗалык җәмгыятьләре җитәкчеләренә (алга таба – муниципаль оешма җитәкчесе һәм хезмәткәре) хезмәт командировкаларына бәйле чыгымнарны кайтару түбәндәге күләмнәрдә гамәлгә ашырыла:

1) муниципаль оешмаларның командировкага җибәрелгән җитәкчеләренә һәм хезмәткәрләренә торак урынны броньлау һәм наемга алу чыгымнары (аларга түләүсез торак урын бирелә торган очраклардан тыш) тиешле документлар белән

расланган чыгымнар буенча һәм кунакханәнең (отельнең) стандарт бер урынлы номеры бәясе буенча 3 500 сумнан артмаган күләмдә кайтарыла;

2) муниципаль оешмаларның командировкага җибәрелгән җитәкчеләренә һәм хезмәткәрләренә торак урыннны броньлау һәм наемга алу чыгымнары (аларга түләүсез торак урын бирелә торган очраклардан тыш) тиешле документлар белән расланган чыгымнар буенча, кунакханәнең (отельнең) бер урынлы номеры бәясе буенча: Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләре буенча – 5 000 сумнан артмаган күләмдә кайтарыла;

3) даими яшәү урыныннан читтә яшәүгә бәйле өстәмә чыгымнар (тәүлеклек), муниципаль оешма җитәкчесенә һәм хезмәткәренә хезмәт командировкасында булган һәр көн өчен, ял һәм бәйрәм көннәрен дә кертеп, шулай ук юлда булган көннәр өчен, шул исәптән юлда мәҗбүри тукталыш вакыты өчен, 700 сум күләмендә кайтарыла.

2. Муниципаль оешма җитәкчеләренең һәм хезмәткәрләренең командировка урынына бару һәм хезмәт функциясен даими узу урынына кире кайту (юл йөрү документларын рәсмиләштерү, поездларда урын-җир әйберләре бирү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләүне дә кертеп), шулай ук бер торак пункттан икенчесенә бару чыгымнары юл йөрү документлары белән расланган фактагы чыгымнар буенча кайтарыла.

3. Башкарма комитетның «Акцияләренең (өлешләренең) йөз проценты Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенә караган муниципаль учреждениеләр, муниципаль унитар предприятиеләр һәм хуҗалык җәмгыятьләре җитәкчеләренә хезмәт командировкасына бәйле чыгымнарны кайтару турында» 2023 елның 9 гыйнварындагы 13 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары А.С. Ганиевка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов